**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**04.07.2015** **№ 472-п**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 24 февралендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” 133-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 16 мартындагы “Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең гомуми күләмен раслау турында” Указына үзгәрешләр кертү хакында” ПУ-289 номерлы Указына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – Министрлык) 2015 елның 20 мартындагы “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль органнарының штат расписаниесе санын кыскарту һәм аңа үзгәрешләр кертү турында” 187-п номерлы боерыгына туры китерү максатларында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 24 февралендәге 133-п номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләгәндә

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлегенә (алга таба – Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемен “Дәүләти экологик күзәтчелек инспекциясе консультанты”, “территориаль идарә консультанты” вазифалары белән тулыландырырга.

2. Документлар башкаруны контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р.Ханнанова) боерыкны Министрлыкның Исемлеккә кертелгән дәүләт хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К.Сәлимгәрәев) боерыкның күчермәсен, аны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алганнан соң өч көнлек срокта, Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр А.Г.Сидоров